| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлегенең Мичурин авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, бала чактан инвалидлар, беренче төркем инвалидлар, студентлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

-Тукай урамында карт агачларны кисү
- Пионерлар һәм Ленин урамнарында грунтлы-вак таш җәелгән юлны ремонтлау
- Сарабиккол авылындабалалар мәйданчыгын җиһазландыру.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол авылы, Киров урамы, 4а адресы буенча урнашкан җирле үзидарә администрациясе бинасында, Киров урамы, 3а адресы буенча урнашкан гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Пионерская урамы, 45 адресы буенча урнашкан «Сатурн - Урал» ҖЧҖ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина